**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы
Айбаш авыл җирлеге Апсабаш торак пунктында
гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

19 июль 2024 ел № 7

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2024 елның 12 июлендә 10 сәгать 00 минутта узган "Биектау муниципаль районы Айбаш авыл җирлегенең Апсабаш авылы торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында 25.10.2023 ел, №1 карарына түбәндәге эш төрләрен өстәү өлешендә үзгәрешләр кертүгә ризамы?:

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (тракторга өстәмә асылмалы җайланма сатып алу) мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре белән беркетмә төзелде

«РИЗА» «КАРШЫ»

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында катнашучы 18 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны 12 кеше тәшкил итә.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучылар түбәндәгечә бүленде:

«РИЗА» позициясе өчен гражданнар җыенында 12 катнашучы тавыш бирде;

«КАРШЫ» позициясе өчен җыенда катнашучы 0 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, гражданнар җыены түбәндәгечә хәл итте:

1. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Айбаш авыл җирлеге Апсабаш торак пунктында гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыены нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.
2. "Биектау муниципаль районы Айбаш авыл җирлегенең Апсабаш авылы торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында 25.10.2023 ел, №1 карарына түбәндәге эш төрләрен тулыландыру өлешендә үзгәрешләр кертүгә ризамы?:

   - торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (тракторга өстәмә асылмалы җайланма сатып алу)

   «РИЗА» «КАРШЫ» -

мәсьәләсе буенча карар кабул ителгән дип санарга.

3. Әлеге карарны мәгълүмати стендларда, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының рәсми сайтында авыл җирлекләре бүлегендә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru/ урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлар регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче Р.Р. Сафиуллин